РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район,
д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
01.07.2021

КАРАР
№ 25

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Арташ авыл җирлеге Башкарма комитеты
тарафыннан расланган 16.06.2021 елгы № 23
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Арташ авыл җирлеге муниципаль торак
фондының социаль наем шартнамәләре һәм
муниципаль торак фондыннан торак урыннарны
яллаучылар өчен торак урыннардан (наемга түләү)
файдаланган өчен түләүне исәпләү тәртибе турындагы
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Төзелеш Министрлыгының 19.06.2017 елгы 892/пр номерлы боерыгы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номеры белән расланган «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү турында» боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннары наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннары наемга алучылар өчен торак урыннардан файдалану (наемга түләү өчен) күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында, Арташ авыл җирлеге Башкарма комитетының 16.06.2021 елгы 23 номеры белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак

фондыннан торак урыннары наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннарыннан (наемга өчен) файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы Нигезләмә” карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Яллаучылар өчен түләү коэффициенты торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) билгеләнгән вакытка – 0,3 күләмендә билгеләнә.

Шул ук вакытта гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен түләүнең ташламалы критерийлары билгеләнә:

- 3 һәм аннан да күбрәк баладан торган күп балалы гаиләләр өчен-0,15;
- пенсионерлар өчен (55 яшькә җиткән хатын-кызлар һәм 60 яшькә җиткән ир-атлар) -0,15;
- инвалидлар өчен – 0,15.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге рәсми сайтында https://saby.tatar.ru/artash адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Арташ авыл
җирлеге башлыгы: А.Р.Әгъләмҗанов